КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 29 сентябрь г.Казань № 884

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 ел, 7 июнь, 432 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 4 апрель, 271 нче; 2020 ел, 24 февраль, 131 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенә, 3.1 нче пунктның алтынчы абзацындагы «гражданнардан» сүзеннән соң «, шулай ук федераль закон, Россия Федерациясе Президенты указы яки Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән гражданнарның башка категорияләреннән» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин